КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 29 май г.Казань № 751

Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 30/2 нче йорт адресы буенча урнашкан «Перинаталь үзәге булган Әлмәт балалар район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Балалар район хастаханәсе), Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 157 нче йорт адресы буенча урнашкан «Әлмәт ашыгыч медицина ярдәме станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Ашыгыч ярдәм станциясе), Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Чехов урамы, 21 нче А йорт адресы буенча урнашкан «Әлмәт стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Стоматология поликлиникасы), Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Тельман урамы, 56 нчы А йорт адресы буенча урнашкан «Әлмәт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – Җәмәгать сәламәтлеге үзәге), Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Тельман урамы, 56 нчы А йорт адресы буенча урнашкан «3 нче Әлмәт шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – 3 нче шәһәр поликлиникасы) Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 30/1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (алга таба – Үзәк район хастаханәсе) кушу рәвешендә, Үзәк район хастаханәсенең исемен һәм эшчәнлегенең төп максатларын саклап, Балалар район хастаханәсен, Ашыгыч ярдәм станциясен, Стоматология поликлиникасын, Җәмәгать

сәламәтлеге үзәген, 3 нче шәһәр поликлиникасын һәм Үзәк район хастаханәсен үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Үзәк район хастаханәсен, Балалар район хастаханәсен, Ашыгыч ярдәм станциясен, Стоматология поликлиникасын, Җәмәгать сәламәтлеге үзәген, 3 нче шәһәр поликлиникасын үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын финанслау 2026 елга Үзәк район хастаханәсенең, Балалар район хастаханәсенең, Ашыгыч ярдәм станциясенең, Стоматология поликлиникасының, Җәмәгать сәламәтлеге үзәгенең, 3 нче шәһәр поликлиникасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Үзәк район хастаханәсен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Үзәк район хастаханәсен, Балалар район хастаханәсен, Ашыгыч ярдәм станциясен, Стоматология поликлиникасын, Җәмәгать сәламәтлеге үзәген, 3 нче шәһәр поликлиникасын үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

законнар нигезендә үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

ел саен Үзәк район хастаханәсе уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә Үзәк район хастаханәсе өчен дәүләт йөкләмәсен расларга;

Үзәк район хастаханәсен, Балалар район хастаханәсен, Ашыгыч ярдәм станциясен, Стоматология поликлиникасын, Җәмәгать сәламәтлеге үзәген, 3 нче шәһәр поликлиникасын үзгәртеп оештыру тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә Үзәк район хастаханәсе уставына тиешле үзгәрешләр кертергә һәм күзәтү советы составын расларга;

Уставка тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң һәм Үзәк район хастаханәсенең күзәтү советы составы расланганнан соң 10 көн эчендә Үзәк район хастаханәсе тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына оператив идарә хокукында Үзәк район хастаханәсенә беркетү өчен Балалар район хастаханәсенә, Ашыгыч ярдәм станциясенә, Стоматология поликлиникасына, Җәмәгать сәламәтлеге үзәгенә, 3 нче шәһәр поликлиникасына оператив идарә хокукында элегрәк беркетелгән мөлкәт (шул исәптән махсус кыйммәтле күчемле мөлкәт) исемлеген һәм күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

әлеге карарның 3 пунктындагы җиденче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң 30 көн эчендә аны оператив идарә хокукында Үзәк район хастаханәсенә беркетергә;

әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә мөлкәт Үзәк район хастаханәсенә беркетелгәннән соң 90 көн эчендә Үзәк район хастаханәсенең гаризасы нигезендә Балалар район хастаханәсендә, Ашыгыч ярдәм станциясендә, Стоматология поликлиникасында, Җәмәгать сәламәтлеге үзәгендә, 3 нче шәһәр поликлиникасында элегрәк даими (чикләнмәгән вакыт) файдалану хокукында булган җир кишәрлеген даими (чикләнмәгән вакыт) файдалану хокукын күчерүне гамәлгә ашырырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин